# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№ 8 29.11.2024 ел.

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының
Иске Матвеевка авыл җирлеге Иске Александровка авылында
2025 елда Гражданнарга үзара салым кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иске Александровка авыл җирлегенең гражданнар җыены нигезендә
Карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иске Александровка авыл җирлегенең Иске Александровка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым акчалары кертергә, көндезге формада укучы студентлардан, I һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия армиясе сафларына чакырылган гражданнардан, мобилизация ләнгәннәргә һәм аларның гаилә әгъзаларыннан.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

-иске Александровка торак пунктында су чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм ҳалыкка су бирүне тәэмин итүче су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (материаллар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү).

3. Әлеге карарны Иске Матвеевка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://menzelinsk.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче __________ Д. Ш. Латыйпов
(имза) (имзаның шифрын ачу)

Иске Матвей авыл җирлеге башлыгы,
җирлек советы рәисе __________ Д. Ш. Латыйпов
(имза) (имзаның шифрын ачу)